**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«06» 02 2023 ел №351

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23-25 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Тукай муниципаль районы уставына, Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2023 елның 27 январендәге халык тыңлаулар беркетмәләренә, Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2023 елның 27 январендәге халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләргә таянып, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты 2022 елның 28 декабрендәге 4255 карарына өстәмә рәвештә

**КАРАР БИРӘ**

1. «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ тарафыннан эшләнгән һәм 2023 елның 27 январендә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Белоус, Ильичевка, Опушка авылларында халык тыңлауларында каралган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешергә.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын халык тыңлаулар беркетмәләре һәм халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр белән Тукай муниципаль районы Советына раслауга җибәрергә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин